Тукай муниципаль районы
Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«17» октябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Калмия авылы җирлегенең Малтабар авылы гражданнар җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (Бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Малтабар авылының зиратын төзекләндерү (зиратка койма сатып алу һәм урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Ә. Гарипов